Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге башкарма комитеты Карары

2014 елның 5 ноябре 85№

Гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлегенең башкарма комитетында муниципаль хезмәтнең конкрет вазыйфалары исемлеген раслау турында һәм муниципаль хезмәткәрләр биләгән очракта керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфаларны раслау хакында.

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, 2007 елның 2 маендагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маендагы «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 559 номерлы Әмере, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге "Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 460 номерлы Әмере, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» УП-701 номерлы Әмере нигезендә Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Әлки муниципаль районы Түбән Әлки

авыл җирлегенең башкарма комитетында муниципаль хезмәтнең конкрет вазыйфалары исемлеген раслау турында һәм муниципаль хезмәткәрләр билгән очракта керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр исемлеген (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: М.Р. Галиуллин

Әлки муниципаль районының
Түбән Әлки авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
2014.05.11. 85№ Карарына
1 нче кушымта

**“Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны билгәндә “Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлеге.**

1. Башкарма комитет сәркатибы